**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге составына керүче Калмаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

19 ноябрь, 2019 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 08 нояберендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:
«Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылы территориясендә 2020 елда балигъ булган, Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнаргаһәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамы буенча күп фатирлы йортларда канализацияне реконструкцияләү проектын эшләү, экспертиза һәм материаллар сатып алу;
- З. Галиев урамы - Үзәк урамы– Яр Чаллы – Калмаш - Игенче автоюлы арасындагы юлга су аша үткәндә тимер киртә урнаштыру;
- Калмаш авылы юлларын ремонтлау;
- юлларны ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу, урам утларын урнаштыру, монтажлау

“ӘЙЕ” “ЮК”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1018 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 536 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 536 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныйрга.

2. «Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылы территориясендә 2020 елда балигъ булган, Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамы буенча күп фатирлы йортларда канализацияне реконструкцияләү проектын эшләү, экспертиза һәм материаллар сатып алу;

- З. Галиев урамы - Үзәк урамы– Яр Чаллы – Калмаш - Игенче автоюлы арасындагы юлга су аша үткәндә тимер киртә урнаштыру;

- Калмаш авылы юлларын ремонтлау;

- юлларны ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу;

- электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу, урам утларын урнаштыру, монтажлау

3. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Габдуллина